**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен гамәлгә кую турында**

Гражданнарны инициатива күрсәтүгә кызыксындыру һәм граждан җәмгыяте институтларын формалаштыруга ярдәм күрсәтү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен гамәлгә куярга.

2. Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү комитетын оештырырга.

3. Түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе турындагы нигезләмәне (1 нче кушымта);

Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү комитеты турындагы нигезләмәне (2 нче кушымта);

Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү комитеты составын (3 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү һәм түләү белән бәйле чыгымнарны Татарстан Республикасы бюджеты хисабыннан финанслауны тәэмин итәргә;

Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү комитеты белән бергәләп Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан

Республикасы Президенты премиясенә лаек булган гражданнарга һәм оешмаларга тапшырыла торган диплом формасын һәм тасвирламасын, почет билгесе рәсемен һәм тасвирламасын эшләргә һәм расларга;

әлеге Указны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

5. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2015 ел, 03 июль
№ ПУ-619

Татарстан Республикасы
Президентының
2015 елның «03» июлендәге
ПУ-619 номерлы Указына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе турында нигезләмә**

1. Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясе (алга таба – Премия) түбәндәгеләргә бирелә:

Россия Федерациясе гражданнарына, социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларга җәмгыятьтә танылган, социаль юнәлештәге коммерциячел булмаган секторның үсешенә әһәмиятле өлеш керткән эшчәнлекләре һәм проектлары, граждан җәмгыяте өлкәсендә югары һөнәри осталыгы белән аерылып торучы, яңа һәм оригиналь фәнни тикшеренүләре өчен;

Россия Федерациясе гражданнарына Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә күп еллар дәвамында үзләреннән әһәмиятле өлеш кертүләре өчен.

2. Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә ел саен Премия түбәндәгечә тапшырыла:

һәрберсе 250 мең сум күләмендә ике Премия – гражданнарга (гражданнар төркемнәренә);

һәрберсе 400 мең сум күләмендә өч Премия – оешмаларга.

3. Премия лауреатына акчалата бүләк, диплом һәм почет билгесе тапшырыла.

Премия гражданнар төркеменә бирелгәндә диплом һәм почет билгесе лауреатларның һәрберсенә тапшырыла, ә акчалата бүләк алар арасында бертигез бүленә.

4. Әгәр Премия алырга теләк белдерүчеләр арасында аны бирүгә лаеклы затлар булмаса яисә лаеклы теләк белдерүчеләр саны ел саен бирелергә тиешле Премия саныннан кимрәк булса, нәтиҗә буларак әлеге Премия бирелми яисә азрак санда бирелә.

5. Премия алырга теләк белдергән затка аның вафатыннан соң яисә кабаттан премия бирелми.

6. Премия алырга теләк белдерүчеләрне Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән коммерциячел булмаган оешмалар, Татарстан

Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары каршындагы җәмәгать советлары, Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлекләрендә төзелгән җәмәгать советлары тәкъдим итә ала.

Премия алырга теләүче гражданнар төркемен тәкъдим иткәндә аның составында биштән дә артык кеше булмаска тиеш.

7. Премия алырга теләүчене тәкъдим итү Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү комитеты (алга таба – Комитет) тарафыннан кабул ителгән тиешле карар «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарылганнан соң 25 календарь көн дәвамында Комитетка карауга түбәндәге документларны һәм материалларны тапшыру юлы белән башкарыла:

а) Премия алырга теләүчене тәкъдим итү турында үтенеч язуы;

б) Премия алырга теләүченең анкета белешмәләре:

Россия Федерациясе гражданы:

Премия алырга теләүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме;

Премия алырга теләүченең туган урыны һәм вакыты;

Премия алырга теләүченең яшәү урыны адресы, аның белән элемтәгә керү өчен мәгълүматлар;

белеме турында мәгълүмат;

Премия алырга теләүченең төп эш яисә хезмәт урыны, биләгән вазыйфасы (төп эш яисә хезмәт урыны булмаганда – шөгыле);

төрле конкурсларда катнашуы һәм аның нәтиҗәләре (нәтиҗәләре булса) турында мәгълүмат;

эшчәнлеге социаль юнәлештәге коммерциячел оешма:

оешманың тулы атамасы;

оешманың гамәлгә куелу вакыты һәм теркәлгән вакыты;

оешманың урнашкан җире;

оешманың эшчәнлек төрләре турында мәгълүмат;

төрле конкурсларда катнашуы һәм аның нәтиҗәләре (нәтиҗәләре булса) турында мәгълүмат;

в) Премия алуга тәкъдим ителү алдыннан килүче елга Премия алырга теләүченең эшчәнлеге турында мәгълүмат;

г) Премия алырга теләүченең Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә керткән өлеше турында мәгълүмат;

д) Премия алырга теләүченең гамәлгә ашырылган проектлары (башлангычлары) тасвирламасы һәм гамәлгә ашырылган проектлары (башлангычлары) йомгаклары буенча ирешелгән социаль өлкәдәге нәтиҗәләр турында ачык күзаллау бирә торган өстәмә материаллар.

8. Комитет Премия алырга теләүчеләргә кагылышлы бирелгән документларны һәм материалларны карауны гамәлгә ашыра, аларның нәтиҗәсе буларак, Татарстан Республикасы Президентына Премияләрне бирү турындагы тәкъдимнәр кертү турында карар кабул итә.

Комитетның Премияләрне бирү турында Татарстан Республикасы Президентына тәкъдимнәр кертүгә кагылышлы карары тиешле документлар һәм материаллар белән Татарстан Республикасы Президентына карауга Премия алырга теләүчеләрне күрсәтү тәмамланган көннән 14 көн дәвамында җибәрелә.

9. Акчалата бүләкне, дипломны һәм почет билгесен тапшыру Татарстан Республикасы Президенты яисә ул вәкаләт биргән зат тарафыннан тантаналы шартларда башкарыла.

Татарстан Республикасы
Президентының
2015 елның «03» июлендәге
ПУ-619 номерлы Указына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү комитеты турында нигезләмә**

1. Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү комитеты (алга таба – Комитет) Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен (алга таба – Премия) бирү чараларын әзерләү һәм уздыруны оештыру максатларында төзелде.

2. Комитет составы Татарстан Республикасы Президенты указы нигезендә раслана.

3. Комитет составына Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары каршындагы иҗтимагый советлар, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә төзелгән иҗтимагый советлар, Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән коммерциячел булмаган оешмалар һәм башка оешмалар, дәүләт органнары вәкилләре кертелә.

4. Комитетка түбәндәгеләр йөкләнә:

а) тәкъдим итүне башларга дигән карар кабул итү һәм әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастыру;

б) Премия алырга теләүчеләргә кагылышлы тапшырылган документларны һәм материалларны карап тикшерү;

в) Татарстан Республикасы Президентына Премия бирү турындагы тәкъдимнәр кертү;

г) бүләкләү документларын рәсмиләштерү, акчалата бүләкне, дипломны һәм почет билгесен тапшыруны оештыру;

д) Премия лауреатларының казанышларын һәм проектларын, фәнни тикшеренүләре нәтиҗәләрен таратуга булышлык күрсәтү.

5. Комитет әгъзалары җәмәгать башлангычларында эшчәнлек алып бара.

6. Комитет үз утырышларына Премия алырга теләүчене тәкъдим иткән Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән коммерциячел булмаган оешмалар, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары каршындагы иҗтимагый советлар, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә төзелгән иҗтимагый советлар вәкилләрен чакырырга хокуклы.

Премия алырга теләүче Комитет утырышында катнаша алмый.

7. Әгәр Комитет әгъзасының шәхсән (турыдан-туры яисә читләтеп) Премия бирү буенча фикер алышу йомгакларында үз мәнфәгатьләре катнашкан булса яисә Комитет әгъзасының Комитет эшендә катнашуына йогынты ясардай башка шартлар булса, аның әлеге Премияне бирү вакытында Комитетның барлык утырышларында катнашырга хакы юк.

Комитет әгъзасының шәхси мәнфәгате булу дигәндә, аның тарафыннан турыдан-туры үзе, аның якын туганнары, шулай ук Комитет әгъзасы финанс яисә башка төрле йөкләмәләр белән бәйләнгән гражданнар яисә оешмалар өчен акчалата яки натураль рәвештә керемнәр, матди файда рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге булу күздә тотыла.

Комитет әгъзасының Комитет эшендә катнашуына йогынты ясавы мөмкин булган шартларга түбәндәгеләр керә:

Премия алырга теләүченең эшчәнлегендә Комитет әгъзасының яисә аның якын туганнарының гамәлгә куючы, коллегиаль орган әгъзасы, бер генә кешедән торган башкарма орган яисә хезмәткәр сыйфатында катнашуы (шул исәптән соңгы 12 ай эчендә);

Премия алырга тәкъдим ителгән оешманың гамәлгә куючысы, анда катнашучы, әгъзасы булган оешма эшчәнлегендә Комитет әгъзасының яисә аның якын туганнарының гамәлгә куючы яисә бер генә кешедән торган башкарма орган сыйфатында катнашуы (шул исәптән соңгы 12 ай эчендә);

Комитет әгъзасының яисә аның якын туганнарының Премия алырга теләүче белән шартнамәгә нигезләнгән мөнәсәбәтләре булу (шул исәптән соңгы 5 ел эчендә);

Комитет әгъзасының яисә аның якын туганнарының Премия алырга теләүчедән акча, башка мөлкәт, матди файда (шул исәптән түләүсез башкарылган эшләр, хезмәтләр рәвешендә) алуы (шул исәптән соңгы 5 ел эчендә);

Комитет әгъзасының яисә аның якын туганнарының Премия алырга теләүче, аны гамәлгә куючы яисә аның җитәкчесе белән судта дәгъвалашу очраклары булу (шул исәптән соңгы 5 ел эчендә);

Комитет әгъзасының Премия алырга теләүче эшчәнлегендә үзе теләк белдереп катнашуы (шул исәптән соңгы 12 ай эчендә);

Комитет әгъзасының шәхси мәнфәгатьләре белән Комитет функцияләре арасында каршылык китереп чыгара торган яисә китереп чыгаруы мөмкин булган башка шартлар.

8. Комитет утырышлары анда составының яртысыннан да ким булмаган санда Комитет әгъзасы катнашканда тулы хокуклы була. Комитет

карарлары утырышта катнашучы Комитет әгъзаларының ачык тавыш бирүе нигезендә гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар бертигез булганда, рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

Комитетның Премия бирү турында Татарстан Республикасы Президентына тәкъдим кертү хакындагы карары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы Комитет әгъзалары тавышының дүрттән өч өлешеннән дә ким булмаган күпчелеге белән кабул ителә.

Комитет әгъзаларының утырышта һәм (яисә) тавыш бирүдә катнашуы мөмкин булмаган очракта, аларның фикере язма рәвештә сораштырып белү юлы белән исәпкә алынырга мөмкин.

9. Тавыш биргәнче Комитетның барлык әгъзалары Премия алырга теләүчеләргә кагылышлы бирелгән документлар һәм материаллар белән танышырга тиеш.

10. Комитетка Комитет рәисе җитәкчелек итә, ул Комитетның эшен планлаштыра, Комитетның утырышларын билгели һәм алып бара.

11. Комитет секретаре Комитет утырышларын әзерләү һәм уздыру буенча оештыру эшен һәм техник эшне башкара, шул исәптән Комитетка карауга кертелгән документларны (мәгълүматларны) тикшерү эшен башкара, шулай ук Комитет карарларын рәсмиләштерә.

12. Комитет карарлары беркетмәләр белән рәсмиләштерелә, аларга Комитет секретаре кул куя һәм Комитет утырышы уздырылган көннән алып өч көн эчендә рәислек итүче тарафыннан раслана.

13. Комитетның эшчәнлеген оештыру һәм матди-техник яктан тәэмин итүне Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы башкара.

Татарстан Республикасы
Президентының
2015 елның « 03 » июлендәге
ПУ- 619 номерлы Указына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларын үстерүгә өлеш керткән өчен Татарстан Республикасы Президенты премиясен бирү комитеты**
**составы**

| | |
|---|---|
| Фомин<br>Анатолий Алексеевич | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе, Комитет рәисе (килешү буенча) |
| Зиннуров<br>Ирек Хәйдәр улы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы, Комитет рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Сафина<br>Зөлфия Нурмөхәммәт кызы | «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Аппараты» дәүләт бюджет учреждениесе җитәкчесе, Комитет секретаре |
| Агапов<br>Олег Дмитриевич | Икътисад, идарә һәм хокук институты (Казан шәһәре) Түбән Кама филиалы директорының фәнни һәм инновация эше буенча урынбасары, «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлеге иҗтимагый советы рәисе (килешү буенча) |
| Бәдриев<br>Илдар Фоат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы |
| Беляков<br>Роман Юрьевич | Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе урынбасары – Граждан җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлек идарәсе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Бикеев<br>Игорь Измаилович | Икътисад, идарә һәм хокук институтының (Казан шәһәре) беренче проректоры, «РОССИЯ ӨЧЕН» ХАЛЫК ФРОНТЫ» Гомумроссия иҗтимагый хәрәкәте төбәк бүлекчәсе рәистәше (килешү буенча) |
| Вавилов<br>Владимир Владимирович | Татарстан Республикасының Лейкемия белән авырый торган балаларга ярдәм итү буенча Анжела Вавилова исемендәге иҗтимагый хәйрия фонды идарә рәисе (килешү буенча) |
| Владимиров<br>Николай Михайлович | Татарстан Халыклар ассамблеясе советы рәисе урынбасары – Татарстан Халыклар ассамблеясе советы Башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Ганибаев<br>Рифат Шаһит улы | бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Бөтенроссия инвалидлар җәмгыятенең «Татарстан Республикасы Инвалидлар җәмгыяте» Татарстан республика оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Забегина<br>Татьяна Вениаминовна | Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзасы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Зарипов<br>Радий Ринат улы | «Татарстан Республикасының армия, авиация һәм флотка ярдәм итү иректе җәмгыяте (ДОСААФ)» иҗтимагый-дәүләт төбәк берләшмәсе идарә рәисе (килешү буенча) |
| Калашникова<br>Ольга Анатольевна | «Россия Федерациясе дәүләт учреждениеләре һәм җәмәгать хезмәт күрсәтүе хезмәткәрләре һөнәр берлеге» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан республика оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Камалетдинов<br>Тимур Ренат улы | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршындагы Иҗтимагый яшьләр палатасы рәисе (килешү буенча) |
| Коноплев<br>Александр Юрьевич | Татарстан Республикасы «Ватан» берләшмәсе» төбәк иҗтимагый яшьләр оешмасы советы рәисе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Мәхмүтов<br>Чыңгыз Госман улы | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы иҗтимагый совет рәисе (килешү буенча) |
| Мишина<br>Любовь Николаевна | «Россия пенсионерлары берлеге» Гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан Республикасы буенча төбәк бүлекчәсе идарә рәисе (килешү буенча) |
| Нәҗипова<br>Гөлчәчәк Рәхимҗан кызы | «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе генераль директоры |
| Пелевин<br>Олег Владимирович | Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары |